ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**27 июнь 2024 ел** **№ 7**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм җирләү эше турында**

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Үлгәннәрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм җирләү эше турында нигезләмәне;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына таләпләрне.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратлары эшчәнлеге тәртибен һәм җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 11 апрелендәге 11 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерел торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Котдусов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы Апаз авыл җирлеге
башкарма комитетының
27 июнь 2024 ел, № 7
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм җирләү эше турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү һәм җирләү эше турында нигезләмә (алга таба- Нигезләмә) «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Үлгәннәрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру һәм җирләү тәртибен җайга сала.

1.2. Нигезлмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

якын туганнар – өске һәм аскы линия буенча туганнар (ата-аналар һәм балалар, бабай, әби һәм оныклар), шулай ук тугандаш һәм тугандаш булмаган (уртак әтисе яки әнисе булган) абыйлар һәм апалар, уллыкка алынганнар, уллыкка алучылар;

дини зират- тиешле дини йолаларны үтәп, бер конфессиягә караган үлгәннәрне яки һәлак булганнарны (алга таба- үлгәннәрне) җирләү өчен билгеләнгән зират (җәмәгать зираты участогы);

җәмәгать зиратының хәрби участогы - үлгән хәрбиләрне һәм аларга тиңләштерелгән категориядәге гражданнарны җирләү өчен билгеләнгән җәмәгать зираты участогы;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге - җирләү вакытында дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатыннан, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге;

җирләү зонасы - зиратның һәм (яки) крематорийның анда җирләү башкарыла торган функциональ-территориаль зонасы;

катафаль ташулар - үлгәннәрнең, җирләү продукциясен һәм җирләүдә катнашучыларның калдыкларын яки көлләрен катафаль транспорт белән ташу;

зират - үлгәннәрнең калдыкларын һәм көлләрен җирләү өчен билгеләнгән җирләү билгеләнешендәге объект;

ирекле күмүләр өчен ябык зират - яңа күмү урыннары булдыру өчен территория тулысынча кулланылган зират;

җирләү чоры - җирләнгән мәетнең минеральләшүе тәмамланган һәм туганнар каберлегенә күмү рөхсәт ителгән вакыт;

колумбарий - көл яки көлле урналарны күмү өчен билгеләнгән бина, аның өлеше яки корылма;

кремация - үлгән кешенең калдыкларын, биологик материалларны утка тапшыру;

җирләү урыны (захоронение) - үлгәннәрнең калдыкларын яки көлләрен күмү өчен билгеләнгән җирләү объекты өлеше;

каберлек (погребение) - үлгәннәрнең калдыкларын, көлләрен һәм көлле урналарны күмү буенча йола гамәлләрен үткәрү өчен билгеләнгән җирләү объектының этик, санитар һәм экологик таләпләргә ярашлы махсус оештырылган өлеше;

минеральләшү-күмелгән мәетнең аерым химик элементларга һәм гади химик кушылмаларга таркалу процессы;

кабер - колумбарийдан башка, җирләү участогында, зиратта, ритуаль корылмада урнашкан һәм үлгән кешенең калдыкларын табутта яки аннан башка, яки көлле урнада җирләү өчен билгеләнгән урын;

кабер коймасы (чардуган)- кабер участогы периметры буенча урнаштырыла торган линияле корылма;

кабер өстенә куелган корылма - анда үлгәннәрнең истәлеген мәңгеләштерү өчен билгеләнгән һәм күмелгән урында урнаштырылган мәгълүмат булган мемориаль архитектура-скульптура корылмасы (кабер ташы);

җәмәгать зираты - үлгәннәрне җирләү урыннары аларның ихтыярын исәпкә алып яки җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт карары буенча каралган зират;

җирләү билгеләнешендәге объект - шәһәр төзелеше яки архитектура комплексы, яки халыкка ритуаль хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән объект, территория яки участок (каберлек, крематорий, колумбарий һ. б.);

ялгыз кабер- җирләү объекты территориясендә бер үлгән кешене, шул исәптән шәхесен эчке эшләр органнары билгеләмәгән кешене җирләү өчен бирелә торган участок;

җирләү - кеше үлгәннән соң аның тәнен (мәетен) санитар һәм башка таләпләргә каршы килмәгән гореф-гадәтләргә һәм традицияләргә ярашлы күмү буенча йола гамәлләре. Җирләү үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) җиргә, утка, суга тапшыру юлы белән башкарыла ала;

өстенә җирләү - үлгән кешене анда элек үлгән туганнарны җирләү башкарылган билгеләнгән тәртиптә бирелгән җирләү урынында җирләү;

туганнар - якын туганнардан тыш, туганлык мөнәсәбәтләрендә торган барлык башка затлар;

туганнар каберлеге - үлгән кешенең туганы элек күмелгән җирләү объекты территориясендәге участок;

санитар-күзәтү зонасы - зират һәм (яки) крематорий һәм торак (селитеб) яки сәнәгать төзелеше арасындагы киңлеге Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән функциональ-территориаль зона;

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт - җирле үзидарә органы тарафыннан түләүсез нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтүче оешма;

җирләү турында таныклык - җирләү турында мәгълүматны һәм җирләү урыны өчен җаваплы кешене үз эченә алган һәм аның җирләү урынын алга таба куллану хокукын раслый торган документ;

эксгумация - суд-медицина яки криминалистик экспертиза өчен яки яңадан җирләү өчен җирләү урыныннан үлгән кешенең мәетен, калдыкларын алу.

## 2. Җирләүне гамәлгә ашыру гарантияләре

2.1. Иренә (хатынына), якын туганнарына, башка туганнарына, үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган законлы вәкиленә үлгән кешене җирләү буенча түбәндәге хезмәтләр исемлеген түләүсез күрсәтү гарантияләнә:
1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү;
3) үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка (крематорийга) илтү;
4) җирләү (кремация һәм аннан соң көлле урнаны бирү).

2.2. Ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яки үлгән кешенең законлы вәкиле булмаганда яки аларның җирләү мөмкинлеге булмаганда, җирләү бурычын үз өстенә алган башка кешеләр булмаганда, шулай ук үлгәннәрнең шәхесләре ачыкланмаган очракта, җирләү буенча хезмәтләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:
1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) киендерү;
3) табут бирү;
4) үлгән кешене зиратка (крематорийга) илтү;
5) җирләү.

Өйдә, урамда яки башка урында үлгән кешене җирләү эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң, Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган очракта, үлем сәбәбен билгеләгәннән соң өч тәүлек дәвамында җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан башкарыла.

Шәхесләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан ачыкланмаган үлгәннәрне җирләү әлеге органнар ризалыгы белән җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан мондый очраклар өчен билгеләнгән җәмәгать зиратларында җирләү юлы белән башкарыла.

2.3. Әгәр җирләү үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган кешеләр акчасына башкарылса, әлеге затларга җирләү буенча хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләр бәясенә тиң күләмдә җирләү өчен социаль пособие түләнә.

2.4. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен Татарстан Республикасы Арча муниципаль

районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бүлеге, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән килештерү буенча билгели.

2.5. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге сыйфаты Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына карата таләпләргә туры килергә тиеш.

## 3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыру

3.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан башкарыла.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәсенә җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә вәкаләтле органның вәкаләтләренең бер өлешен (аерым вәкаләтләрен) бирү рөхсәт ителә.

3.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт (алга таба – махсуслаштырылган хезмәт) башкара.

3.3. Вәкаләтле орган һәм махсуслаштырылган хезмәт үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары һәм җирләү һәм җирләү эше өлкәсендәге башка норматив хокукый актларга таяна.

3.4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыру әлеге Нигезләмәгә һәм җирләү һәм җирләү эше өлкәсендәге башка норматив хокукый актларга ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5. Җирләү эшен финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

3.6. Кулланылган милеккә ия булу, куллану һәм идарә итү җирләү һәм җирләү эшен оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту өлкәсендәге вәкаләтләр

4.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту өлкәсендә вәкаләтле органның вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә бердәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм җирләү эше мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль хокукый актлары таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) махсуслаштырылган хезмәтнең җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген түләүсез нигездә күрсәтүен, шул исәптән гарантияләнгән җирләү буенча хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына карата таләпләрне үтәвен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма хакимиятенең республика органнары һәм җирле үзидарә органнары белән җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә финанс, бюджет, инвестиция, бәя, тариф сәясәте һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итүе;

5) Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча пенсия һәм социаль иминият фонды бүлеге, түләүсез нигездә күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән билгеләү һәм килештерү;

6) үз компетенциясе чикләрендә җирләү һәм җирләү эше мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны эшләү һәм кабул итү;

7) җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге кысаларында махсус хезмәт белән төзелгән контрактларны (килешүләрне) үтәүгә юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең контрольдә тотылуын гамәлгә ашыру;

8) Апаз авыл җирлеге территориясендә (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы) җәмәгать зиратлары территориясендә башкарылган барлык җирләүләрне исәпкә алу, шул исәптән каберлекләрне теркәү китабын алып бару;

9) җирләү зоналарын билгеләү һәм җәмәгать зиратларында җирләү өчен урыннар бирү;

10) үлгән кешене җирләү өчен зират территорияләрендә бушлай бирелә торган җир участогы күләмен билгеләү;

11) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратларын ачу һәм ябу турында карарлар кабул итү;

12) яңа зиратлар төзү, булган җәмәгать зиратларын киңәйтү, күчерү, ябу буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

13) зиратларны һәм башка җирләү объектларын максатчан билгеләнеше буенча куллануны контрольдә тоту;

14) җирләү билгеләнешендәге объектларны саклауны оештыру;

15) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыруның торышына ел саен мониторинг үткәрү;

16) җирләү эше мәсьәләләре буенча (аларны формалаштыру тәртибен һәм вәкаләтләрен билгеләп) Попечительлек (күзәтү) советлары булдыру;

17) гражданнарга консультация бирү һәм җирләү һәм җирләү эше өлкәсендәге мәсьәләләр буенча кабул итү;

18) гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә башка вәкаләтләр.

4.2. Махсус хезмәт гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеген, шулай ук башка вәкаләтләрне түләүсез нигездә күрсәтә.

## 5. Җирләү урыннары

5.1. Җирләү урыннары булып этик, санитар һәм экологик таләпләргә ярашлы рәвештә үлгәннәрнең җәсәдләрен (мәетләрен), үлгәннәрнең көлләре салынган урналарны күмү өчен төзелгән зиратлар, шулай ук үлгәннәрне җирләү өчен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар булган җир кишәрлекләре тора.

5.2. Җирләү урыннарын булдыру турында карар гамәлдәге закон таләпләренә ярашлы рәвештә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

5.3. Җирләү урыннары даими су басу, давыллар, җир тетрәүләр һәм башка табигать афәтләреннән соң, хәрби каберлекләрдән тыш, вәкаләтле орган карары буенча гына күчерелә ала.

5.4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендәге җәмәгать зиратлары ачык, ирекле җирләү өчен ябык, ябык булырга мөмкин.

5.5. Җәмәгать зиратлары территориясендә җирләү урыннары:

1) ялгыз;

2) туганнар;

3) дин тотучылар;

4) шәрәфле;

5) хәрбиләр.

5.6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә хәрби җирләүләр (хәрби участоклар), бер диндә үлгәннәрне шәрәфле җирләүләр һәм җирләүләр (дини участоклар), шулай ук колумбарийлар өчен аерым җир кишәрлекләре (зоналар) каралырга мөмкин.

Зиратның хәрби участокларында җирләү өчен үлгән кешенең 8-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән гражданнар категориясенә каравын раслый торган документлар бирелә.

5.7. Җирләү зонасы кварталларга һәм участокларга бүленә.

5.8. Үлгән кешенең гәүдәсе белән табутны күмү өчен каберләр казыганда, җирле шартларга (туфракның характерына һәм җир асты суларының тору дәрәҗәсенә) бәйле рәвештә, кабернең тирәнлеген билгеләргә кирәк. Шул ук вакытта кабернең озынлыгы 2 метр, киңлеге 1 метр, тирәнлеге 1,5 метрдан ким түгел. Барлык очракларда да кабер төбенең билгесе җир асты сулары дәрәҗәсеннән 0,5 метрга югарырак булырга тиеш.

5.9. Җирләү урыннары җәмәгать зиратының билгеләнгән планлаштыруына ярашлы бирелә. Җирләү урыннары арасы киңлеге 0,5 метрдан ким була алмый.

5.10. Стена урнаштырганда, аның зурлыгы җирләү өчен бүлеп бирелгән участокның норматив зурлыгына туры килергә тиеш. Капканың биеклеге 1,5 метрдан артмаска тиеш. Кабер ташының биеклеге 2,5 метрдан артмаска тиеш.

5.11. Зиратның билгеләнгән планлаштыруын бозып, шул исәптән җирләү урыннары арасында, юл кырыенда һәм санитар-күзәтү зонасы чикләрендә җирләү рөхсәт ителми.

## 6. Ялгыз каберләр

6.1. Ялгыз каберлекләр вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

6.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә ялгыз күмү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлеге күләме 2 кв.м (2,0 м х 1,0 м) тәшкил итә.

6.3. Ялгыз кабер өчен урын бирү турында гариза үлгән кешенең ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яки законлы вәкилләре, үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка кешеләр (алга таба гариза бирүче) теләсә нинди формада кәгазьдә, турыдан – туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә бирелә.

6.4. Ялгыз кабер өчен урын бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушыла:

1) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр гариза бирүченең вәкиле ялгыз җирләү өчен урын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

4) кремация турында белешмәнең күчермәсе (көлле урнаны күмгәндә) (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

5) үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәве фактын раслый торган ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән документ;

6) Эчке эшләр органнарының үлгән кешене җирләүгә ризалыгын раслаучы документ, аның шәхесе Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокларда билгеләнмәгән очракта.

7) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык.

6.5. Ялгыз кабер өчен урын бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) кирәкле зират җирләү өчен ябык;

2) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

3) тапшырылган документларда объектив рәвештә аларның чынлыгын тикшерүне кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яки дөрес булмаган мәгълүмат булу.

6.6. Ялгыз кабер өчен урын бирүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, вәкаләтле орган баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, ялгыз җирләү өчен урын бирүдән баш тартуны рәсмиләштерә.

6.7. Ялгыз җирләү өчен урын бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, вәкаләтле орган:

гариза бирүче белән берлектә җирләү урыны булган җир кишәрлеген бүлеп бирү максатыннан зиратны тикшерә;
ялгыз җирләү өчен урын бирү турында карар кабул итә;
җирләү урынын теркәү китабында теркәп бара.

6.8. Ялгыз җирләү өчен урын бирү яки ялгыз җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

6.9. Ялгыз җирләү өчен урын бирү яки ялгыз җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар гариза бирүчегә шәхсән документ формасында кәгазьдә бирелә.

## 7. Туганнар каберлеге

7.1. Туганнар өчен җирләү урыны (каберлеге) вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез бирелә.

7.2. Туганнар өчен җирләү урыннары ир белән хатынны, якын туганнарны һәм башка туганнарны җирләү мөмкинлеген исәпкә алып бирелә.

7.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә туганнарны җирләү өчен түләүсез бирелә торган җир кишәрлеге күләме 5 кв.м (2,0 м х 2,5 м) тәшкил итә.

7.4. Туганнарны җирләү өчен урын бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә ирекле формада бирелә.

7.5. Туганнарны җирләү өчен урын бирү турында гаризага түбәндәге документлар кушыла:

1) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр гариза бирүченең вәкиле туганнарны җирләү өчен урын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә икән, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

4) кремация турында белешмәнең күчермәсе (көлле урнаны күмгәндә) (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

5) үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәве фактын раслый торган ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән документ;

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык.

7.6. Гаризаны карау, туган җирләү өчен урын бирү яки туган җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.5-6.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

## 8. Шәрәфле каберлекләр

8.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге җәмәгать зиратлары территориясендә Россия Федерациясе, Татарстан

Республикасы, Арча муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге алдында аерым казанышлары булган мәрхүмнәрне җирләү өчен шәрәфле җирләүләр (каберлекләр) өчен кишәрлекләр (зоналар) булдырылырга мөмкин.

8.2. Шәрәфле җирләү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

8.3. Шәрәфле җирләү урыннарында түбәндәге категория гражданнарны җирләү гамәлгә ашырыла:

1) Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары;

2) Социалистик Хезмәт Геройлары;

3) Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары;

4) I, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнгәннәр, Дан орденының тулы кавалерлары;

5) I, II һәм III дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары белән бүләкләнгәннәр, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары;

6) Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар;

7) Татарстан Республикасы Арча районының Мактаулы гражданнары;

8) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы һәм Апаз авыл җирлеге үсешенә өлеш керткән предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләре.

8.4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә шәрәфле җирләү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлеге күләме 2 кв.м (2,0 м х 1,0 м) тәшкил итә.

8.5. Шәрәфле җирләү урыны бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә ирекле формада бирелә.

8.6. Шәрәфле җирләү өчен урын бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушыла:

1) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр гариза бирүченең вәкиле хөрмәтле җирләү өчен урын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә икән, шулай ук гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

3) үлгән кешенең Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы алдындагы тиешле хезмәтләрен раслаучы документлар (хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәләренең күчермәләре яки башка документлар, таныклыклар һәм бүләкләрнең төп нөсхәләре);

4) үлем турында таныклык күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

5) кремация турында белешмәнең күчермәсе (көлле урнаны күмгәндә) (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык.

8.7. Гаризаны карау, шәрәфле җирләү өчен урын бирү яки шәрәфле җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.5-6.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

## 9. Хәрби каберлекләр

9.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә хәрби җирләүләр (каберлекләр) өчен аерым җир кишәрлекләре (зоналар) (хәрби участоклар) каралырга мөмкин.

9.2. Хәрбиләр өчен җирләү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

9.3. Хәрби участокларда үлгәннәрне җирләү рөхсәт ителә, алар үлгән кешенең ихтыярын яки тормыш иптәшенең, якын туганнарының яки башка туганнарының теләгөн исәпкә алып, 8-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясының 1 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән.

9.4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә хәрби күмү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлеге күләме 2 кв.м (2,0 м х 1,0 м) тәшкил итә.

9.5. Хәрби каберлеккә урын бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә ирекле формада бирелә.

9.6. Хәрби каберлек өчен урын бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушыла:

1) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр гариза бирүченең вәкиле хәрби ккаберлек өчен урын бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә икән, шулай ук гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

4) кремация турында белешмә күчермәсе (көлле урнаны күмгәндә)(тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

5) үлгән кешенең җәмәгать зиратының хәрби участогында күмелергә мөмкин булган кешеләр категориясенә керүен раслый торган документлар.

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык.

9.7. Гаризаны карау, шәрәфле җирләү өчен урын бирү яки шәрәфле җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.5-6.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

## 10. Өстенә җирләү

10.1. Гамәлдәге кабер өстенә  җирләү, санитар нормаларны үтәп, буш урын булганда башкарыла. Каберләр арасындагы ара (кабер белән урна арасында, урна белән урна арасында) вертикаль һәм горизонталь буенча 0,5 м-дан ким булмаска тиеш, һәм җир катламы белән тутырыла. Җир катламының калынлыгы табутларның өске өлешеннән өскә кадәр 1 метрдан ким булмаска тиеш.

10.2. Җирләү минеральләшү чоры тәмамланганнан соң гына башкарыла, әмма соңгы җирләүдән соң 15 елдан да иртәрәк түгел.

Кремациядән соң көл салынган урнаны күмү соңгы җирләү вакытына карамастан башкарыла.

10.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендәге зиратларда туганнар, шәрәфле, хәрби каберлекләр урынында җирләүгә рөхсәт бирү түләүсез нигездә башкарыла.

10.4. Җирләүгә рөхсәт бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә ирекле формада бирелә.

10.5. Җирләүгә рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушыла:

1) җирләү турында таныклык (җирләү турында таныклык булмаган очракта, вәкаләтле орган каберләрне теркәү китабында җирләү урыны теркәлгән кеше турында мәгълүмат булуын билгели);

2) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (тикшерү өчен төп нөсхә кушымтасы белән);

